| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге** |

| | |
|---|---|
| **КАРАР**<br>**31.03.2026 ел** | **КАРАР**<br>**№24** |

Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 статьясы, «Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указының 4 пунктын үтәү турында" Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2026 елның 13 мартындагы 09/13-09/1259 номерлы хаты, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге Советы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советынаң түбәндәге карарларының үз көчен югалтуын таныргa:

- 2017 елның 21 августындагы 48 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларына контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау турында»;

- 2021 елныд 16 июлендәге 29 номерлы «2017 елның 21 августындагы 60 номерлы Совет карары белән расланган «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибе һәм «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм башкарма комитет җитәкчесенең

контракт буенча вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»;

- 2022 елның 13 июлендәге 52 номерлы «Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» халыкка житкерергә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл жирлеге
Советы рәисе

Р.Ә.Исламова